ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*Постановление* *Карар*

22.04.2019 Чистай шәһәре №209

Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь
төзелеш объектларын
реконструкцияләүнең чик
параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендә кабул ителгән 1016нчы карары белән расланган рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Регламентның 2.9нчы пунктында:
“дәүләт” сүзен “муниципаль” сүзенә алмаштырырга”

3нче пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә: рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү турында комиссиянең тискәре тәкъдимнәре”;
түбәндәге эчтәлектәге 5нче пунктча белән тулындырырга: “катларның чик саны, бинаның, төзелешнең, корылманың чик биеклеге өлешендә һәм федераль яки төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектур карарларына таләпләрдә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын

реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт ителми”.

1.2. Регламентның 2.4нче пунктындагы беренче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

“Җирле хакимият башлыгы әлеге матдәнең 5нче өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр кергәннән соң җиде көн дәвамында рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү турында яки шундый рөхсәтне бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карарның сәбәбен күрсәтеп, карар кабул итә”.

1.3. Регламентның 5.1. пунктының 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: “дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны теркәү срогын бозу, сорау 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән”.

1.4. Регламентның 5.4. пунктның 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: “дәүләт яки муниципаль хезмәтне үз вакытында һәм дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты нигезендә алу”.

1.5. Регламентның 5.7. пунктның 1 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган булса”.

2. “Шәһәр төзелеше һәм инфраструктура үсеше” МБУнә әлеге карарны ТРның хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов